күп профильле
18 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

# Мәктәп яңалыклары...

5 нче чыгарылыш
31 нче гыйнвар

БУ САНДА:

Яңалыклар 1—2

Мәктәп формасы кирәкме? Сораштырулар 3

Ул көннәр мәңгегә онытылмас... 4

## Укытучылар эш тәҗрибәләре белән уртаклаша...

11 нче гыйнвар көнне мәктәбебездә «ФГОС ны тормышка ашыру шартларында, белем бирү сыйфатын күтәрү өчен төп шартлар» темасына педсовет булып узды.

Башлангыч сыйныф укытучылары Нәҗмиева Д.И., Гиниятуллина А.А., география һәм биология укытучысы Рузинова О.П., инглиз теле укытучысы Мөхәммәтҗанова Р.Н. эш тәҗрибәләре белән уртаклашты.

Педсовет темасы буенча директор урынбасарлары Данилевская И.Ф., Перемитина А.Х., педагог-психолог Абсалямова И.Р. та чыгыш ясады.

Педсовет нәтиҗәле узды.

Олимпиада, конференциядә җиңүче укучыларны әзерләүче укытучыларга грамоталар тапшырылды, рәхмәт сүзләре җиткерелде.



## “Ел укытучысы - 2021”

Казан шәһәренең “Ел укытучысы - 2021" Бөтенроссия һөнәри осталык конкурсының шәһәр этабында "Тормыш иминлеге нигезләре" номинациясендә уңышлы чыгыш ясавы белән тормыш иминлеге нигезләре укытучысы Галиәхмәтов Айнур Харис улын котлыйбыз! Яхшы һәм уңай нәтиҗәләр көтеп калабыз! Уңышлар Сезгә!



21 нче гыйнварда, «Уңышлы шәхесләр белән әңгәмә» мәктәп проектында, «Игелекле эшләр» @blagie.dela хәйрия фонды президенты Алия Илгиз кызы һәм Алсу Гадил кызы Кривель, әлеге фонд программалары җитәкчесе булды. Алар безгә үз оешмаларының эше, кешеләргә ярдәм итүнең мөһимлеге, әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булырга кирәклеге турында сөйләделәр. Безнең очрашуыбызның төп сүзләре - Алия Илгиз кызыннан һәм Алсу Гадил кызыннан: «Ходайның сезнең колларыгыздан башка куллары юк!».



19 нчы гыйнвардан 24 нче гыйнварга кадәр безнең мәктәптә музыка, сынлы сәнгать һәм технология атналыгы уза. Укытучы Лицова Л.А. укытучыларның үзләре катнашында «Бусагада кунаклар булганда» дигән файдалы мастер-класс үткәрде.

30 минут эчендә без беренче аш-су, төрле төрдәге салатлар һәм хәтта камыр ризыклары әзерләдек.

# Мәктәп формасы

Россиядә мәктәп формасы кертелүнең төгәл датасы бар. Ул якынча 1834 нче ел белән исәпләнә. Нәкъ менә шушы елда гражданнар мундирларының аерым төрләрен раслаучы закон кабул ителә. Гимназистлар һәм студентлар мундиры да шуңа карый. Шул чор малайлары өчен тәгаенланган костюмнар хәрби һәм штатский ирләр күлмәгенең үзенчәлекле яраклашуы белән аерылып торган. Бу костюмны дәрестән тыш вакытларда да киеп йөргәннәр.

Хәзерге көндә һәр мәктәпнең үз формасы бар. Безнең мәктәбебезнең дә үз формасы бар. Аны барлык укучылар мәҗбүри киеп йөрергә тиеш.

Кызларның формасы:зәңгәр төстәге итәк, яки чалбар, ак күлмәк, зәңгәр төстәге галстук-галка, мәктәп эмблемасы, туфли. Ә егетләргә килгәндә, аларның формасы: зәңгәр төстәге костюм, зәңгәр галстук, мәктәп эмблемасы, туфли.

Бердәм мәктәп формасының файдасы, я зыяны турында да бердәм фикер юк. Форма кирәкме дигән сорауга да җавап юк. Бер нәрсә бәхәссез: мәктәп формасы бары мәктәптә генә киелә торган кием булырга тиеш. Аның уңайлы, кер күтәрә торган, натураль тукымалардан гына тегелгән булуы шарт. Без балаларны сакларга тиеш.



## Сораштыру


## Укучылар белән әңгәмә

-Сез мәктәп формасын киеп йөрүгә ничек карыйсыз? Мәктәп формасын киеп йөрисегез киләме?

-Әйе, безгә форма киеп йөрү ошый, -диделәр башлангыч сыйныф укучылары.

-Юк, без башка төрле форма киеп йөрер  идек, -диделәр, күпчелек урта һәм югары сыйныф укучылары.

-Ә сез нindине кияр идегез?



-Без блузка,  модный чалбар кияр идек.  Без джинсы кияр идек, дип тә өстәделәр югары сыйныф укучылары.

Кадерле укучылар! Укытучылар һәм эти-әниләрнең күбесе сезнең мәктәп формасыннан йөрүегезне кулай күрә. Беренчедән ,  бу  билгеле бер тәртипкә, төгәллеккә өйрәтеп торса; икенчедән, чуарлыктан саклый, дип саный алар. Без дә шундый фикердә.

Газета хәбәрчеләре

# Ул көннәр мәңгегә онытылмас... Ленинград блокадасы

Ленинград 1941 елның 8 сентябреннән 1944 елның 27 гыйнварына кадәр - 872 көнгә камалышта кала. Анда яшәүчеләр өчен бу үлем исе аңкып торган иң авыр 872 көн була. Зур шәһәрләрне шулай озак саклауга мисаллар хәтта дөнья тарихында да юк. Шәһәрдә 2,5 миллион кеше кала. Ленинградның тиңдәшсез батырлыгы тарихка халыкның гаҗәеп кыюлыгы һәм геройлыгы эпопеясы булып кереп калды.

Камалышның беренче көннәреннән үк фашистлар шәһәрне вәхшиләрчә бомбага тота башлыйлар. Иң кыены - сугышчыларны һәм шәһәр кешеләрен азык-төлек белән тәэмин итү. Булган запас тиз арада юкка чыга. 1941 елның 2 сентябреннән азык-төлеккә карточкалар кертелә. 1941 елның 25 декабреннән Ленинградта яшәүчеләр: эшләүчеләр - 350 грамм, хезмәткәр, балалар һәм кеше тәрбиясендә булучылар 200 грамм ипи ала башлыйлар. Ашау нормасы биш тапкыр киметелә. Кайгы һәр гаиләгә килә. Әти-әниләренең күз алдында уллары һәм кызлары үлә, балалар ятим кала. Күп гаиләләр тулысы белән үлеп бетәләр. Йортларда, урамнарда, кая карама - үле гәүдәләр, аларны хәтта җирләп тә өлгерә алмыйлар. Әмма бу ленинградлыларны тез чүктерә алмый.

Камалыштагы шәһәрне коткару өчен азык-төлек, корал бердәнбер юл - Ладога күле аша озатыла. Бу - боз каткан күл буйлап узучы данлыклы "Яшәү юлы". Шәһәрдән кешеләрне дә шушы юлдан алып чыгалар. Аннан 152 көн файдаланалар. Нәтиҗәдә йөз меңләгән ленинградлы ач үлемнән йолып калына. Беренче кыштан соң яз җитә. Ул беренчесенә караганда бераз җиңелрәк була. Шәһәр бирешми. Ул үзен геройларча яклый.

Кадерле укучылар! Безнең бүгенге көнебез аяз, күгебез тыныч, ризыгыбыз мул. Без бик бәхетле! Тарихны онытмыйк, бүгенге көнгә шатланып яшик!Күгебез һәрчак аяз булсын!

Тулпар урамы, 2нче йорт
Телефон: 89050229576
Эл. почта: gabdullazyanova1979@mail.ru
Редколлегия:
Сафина Камилла, Соколова София, Овезова Ләйлә, Әхмәтҗанова Рузинә
Җитәкчесе: Габдуллаҗанова А.Ф.